ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

1 июль,2024 ел № 34/6

Шәһәр Советының «Даими рәвештә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең һәм Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүче затларның хезмәтенә түләү системасы турында» 2018 елның 27 апрелендәге 24/6 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, сайлап куела торган вазыйфаи затларның, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 30 апрелендәге 182 номерлы карары, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының «Даими рәвештә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең һәм Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүче затларның хезмәтенә түләү системасы турында» 2018 елның 27 апрелендәге 24/6 номерлы Карарына (Шәһәр Советының 2018 елның 10 августындагы 26/14, 2020 елның 23 сентябрендәге 1/12, 2021 елның 3 ноябрендәге 9/4, 2021 елның 27 декабрендәге 11/5, 2022 елның 2 ноябрендәге 17/5, 2022 елның 8 декабрендәге 18/6, 2023 елның 28 декабрендәге 29/6 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 2 пунктның 1 пунктчасында «12 688» саннарын «13 323» саннарына алыштырырга;

2) даими рәвештә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең һәм Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүче затларның хезмәтенә түләүне формалаштыру нормативларына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 2 пунктның 4 пунктчасында «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алыштырырга;

- 8.4 пунктта:

1 пунктчада «3,22175» саннарын «3,8249» саннарына алыштырырга;

2 пунктчада «1,57994» саннарын «1,9485» саннарына алыштырырга;

3 пунктчада «1,22485» саннарын «1,5427» саннарына алыштырырга;

4 пунктчада «1,08388» саннарын «1,3815» саннарына алыштырырга;

- 15 пунктта:

5 пунктчада «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алыштырырга;

6 пунктчада «һәм катлаулы биремнәр» сүзләреннән соң «максималь зурлык белән чикләнмәгән, хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә» сүзләрен өстәргә;

- 17 пунктта:

3 пунктчада «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлектәге 7 пунктча өстәргә:

«7) түләү тәртибен җирле үзидарә органының бурычларын һәм функцияләрен тәэмин итүне, вазыйфаи инструкцияне үтәүне исәпкә алып тиешле җирле үзидарә органы җитәкчесе билгеләп торган аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премияләр - вазыйфаи окладның бер проценты күләмендә.»;

- 18 пунктта:

1 пунтчада 7 таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7 таблица

Вазыйфаи окладлар күләме

| Вазыйфаның исеме | Арттыру коэффициенты, (процент) | Вазыйфаи оклад күләме (сумнарда) |
|---|---|---|
| Башкарма комитетның идарә, башка структура бүлекчәсе составындагы бүлек башлыгы | 1,78 | 23 715 |
| Бүлекчә мөдире | 1,73 | 23 049 |
| Баш белгеч | 1,66 | 22 117 |
| Әйдәүче белгеч | 1,52 | 20 251 |
| 1 категорияле белгеч | 1,35 | 17 987»; |

4 пунктчада «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлектәге 9 пунктча өстәргә:

«9) түләү тәртибен җирле үзидарә органының бурычларын һәм функцияләрен тәэмин итүне, вазыйфаи инструкцияне үтәүне исәпкә алып тиешле җирле үзидарә органы җитәкчесе билгели торган аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премияләр.»;

3) 2 кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шәһәр Советының
24/6 Карарына
2 нче кушымта
27 апрель, 2018 ел

Шәһәр Хакимен, муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасарын, Контроль-хисап палатасы Рәисен, Рәис урынбасарын, аудиторын айлык акчалата бүләкләү күләме

| Вазыйфа исеме | Айлык акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Шәһәр Хакиме | 44 041 |
| Муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары | 39 637 |
| Контроль-хисап палатасы Рәисе | 39 637 |
| Контроль-хисап палатасы Рәисе урынбасары | 36 770 |
| Контроль-хисап палатасы аудиторы | 29 444»; |

4) 3 кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шәһәр Советының
24/6 Карарына
3 нче кушымта
27 апрель, 2018 ел

Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмен исәпләгәндә кулланыла торган арттыру коэффициентлары һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләме

| Вазыйфа исеме | Арттыру коэффициенты (процент) | Вазыйфаи оклад күләме (сум) |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 3,26 | 43 433 |
| Шәһәр  Хакиме (Шәһәр Советы) аппараты җитәкчесе; | 3,16 | 42 101 |

| | | |
|---|---|---|
| Шәһәр Хакиме (Шәһәр Советы) аппаратының эшләр идарәчесе;<br>Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары;<br>Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары;<br>Башкарма комитетның район хакимияте башлыгы | | |
| Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе;<br>Башкарма комитетның эшләр идарәчесе | 3,08 | 41 035 |
| Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе урынбасары;<br>Башкарма комитетның эшләр идарәчесе урынбасары | 2,76 | 36 772 |
| Шәһәр Хакиме (Шәһәр Советы) аппараты идарәсе башлыгы;<br>Башкарма комитет идарәсе башлыгы;<br>Контроль-хисап палатасы идарәсе башлыгы;<br>Башкарма комитетның район хакимияте башлыгының беренче урынбасары;<br>Башкарма комитетның район хакимияте башлыгы урынбасары | 2,30 | 30 643 |
| Башкарма комитетның башка структура бүлекчәсе җитәкчесенең беренче урынбасары;<br>Шәһәр Хакиме (Шәһәр Советы) аппараты идарәсе башлыгының беренче урынбасары;<br>Башкарма комитет идарәсе башлыгының беренче урынбасары;<br>Шәһәр Хакиме (Шәһәр Советы) аппараты идарәсе башлыгы урынбасары;<br>Башкарма комитет идарәсе башлыгы урынбасары;<br>Контроль-хисап палатасы идарәсе башлыгы урынбасары | 2,12 | 28 245 |
| Шәһәр Хакиме (Шәһәр Советы) аппаратының мөстәкыйль бүлеге башлыгы (мөдире)<br>Башкарма комитетның мөстәкыйль бүлеге башлыгы (мөдире);<br>Шәһәр Хакиме (Шәһәр Советы) аппаратының башка структура бүлекчәсе җитәкчесе<br>Башкарма комитетның башка структура бүлекчәсе җитәкчесе;<br>Контроль-хисап палатасының мөстәкыйль бүлеге башлыгы (мөдире) урынбасары | 2,21 | 29 444 |
| Башкарма комитетның район хакимияте аппараты җитәкчесе | 2,29 | 30 510 |

| | | |
|---|---|---|
| Шәһәр Хакиме (Шәһәр Советы) аппаратының мөстәкыйль бүлеге башлыгы (мөдире) урынбасары;<br>Башкарма комитетның мөстәкыйль бүлеге җитәкчесе (мөдире) урынбасары;<br>Башкарма комитетның башка структура бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары;<br>Контроль-хисап палатасының мөстәкыйль бүлеге башлыгы (мөдире) урынбасары | 1,82 | 24 248 |
| Яр Чаллы шәһәре Хакиме ярдәмчесе;<br>Башкарма комитет Җитәкчесе ярдәмчесе;<br>Яр Чаллы шәһәре Хакиме киңәшчесе;<br>Башкарма комитет Җитәкчесе киңәшчесе;<br>Башкарма комитетның идарә, башка структура бүлекчәсе составындагы бүлек башлыгы;<br>Башкарма комитетның район хакимияте бүлеге башлыгы;<br>Контроль-хисап палатасы идарәсе составында бүлек башлыгы | 1,78 | 23 715 |
| Башкарма комитетның идарә, башка структура бүлеге составындагы бүлекчә башлыгы;<br>Башкарма комитетның мөстәкыйль бүлеге составында бүлекчә мөдире;<br>Башкарма комитет структурасында мөстәкыйль бүлекчә мөдире;<br>Контроль-хисап палатасы идарәсе составындагы бүлекчә мөдире;<br>Контроль-хисап палатасының мөстәкыйль бүлеге составындагы бүлекчә мөдире;<br>Башкарма комитетның идарә, башка структура бүлекчәсе составындагы бүлек башлыгы урынбасары;<br>Башкарма комитетның район хакимияте бүлеге башлыгы урынбасары;<br>Контроль-хисап палатасының мөстәкыйль бүлекчәсе мөдире | 1,73 | 23 049 |
| Шәһәр Хакиме (Шәһәр Советы) аппаратының идарә, бүлек, башка структура бүлекчәсе баш белгече;<br>Башкарма комитетның идарә, бүлек, бүлекчә, башка структура бүлекчәсе баш белгече;<br>Контроль-хисап палатасының идарә, бүлек, бүлекчәсе баш белгече;<br>Контроль-хисап палатасы аппараты баш инспекторы | 1,66 | 22 117 |
| Шәһәр Хакиме (Шәһәр Советы) аппаратының идарә, | 1,52 | 20 251 |

| | | |
|---|---|---|
| бүлек, башка структура бүлекчәсе әйдәүче белгече;<br>Башкарма комитетның идарә, бүлек, бүлекчә, башка структура бүлекчәсенең әйдәүче белгече;<br>Контроль-хисап палатасының идарәсе, бүлеге, бүлекчәсе баш белгече;<br>Контроль-хисап палатасы аппаратының әйдәүче инспекторы | | |
| Шәһәр Хакиме (Шәһәр Советы) аппаратының идарә, бүлек, башка структура бүлекчәсенең 1 категорияле белгече;<br>Шәһәр Хакиме (Шәһәр Советы) аппаратының идарә, бүлек, башка структура бүлекчәсенең 2 категорияле белгече;<br>Шәһәр Хакиме (Шәһәр Советы) аппаратының идарә, бүлек, башка структура бүлекчәсе белгече;<br>Башкарма комитетның идарә, бүлек, бүлекчә, башка структура бүлекчәсенең 1 категорияле белгече;<br>Башкарма комитетның идарә, бүлек, бүлекчә, башка структура бүлекчәсенең 2 категорияле белгече;<br>Башкарма комитетның идарә, бүлек, бүлекчә, башка структура бүлекчәсе белгече;<br>Контроль-хисап палатасының идарә, бүлек, бүлекчәсенең 1 категорияле белгече;<br>Контроль-хисап палатасының идарә, бүлек, бүлекчәсенең 2 категорияле белгече;<br>Контроль-хисап палатасының идарә, бүлек, бүлекчә белгече;<br>Контроль-хисап палатасы аппараты инспекторы | 1,35 | 17 987 |

2. Әлеге Карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.
3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев